*#студентлардөньясы*

# *Көллият сулышы*

***№ 4***

***01/2023***

***2023 нче ел***

Россиядә педагог һәм остаз елы

Татарстанда милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы



# *Я Ң А Л Ы К Л А Р*



10 нчы гыйнвар көнне Арча педагогия көллиятендә Укытучы һәм остаз елына багышланган “Алдынгы галимнәр – Татарстан укытучыларына” төбәкара кышкы педагогик сессия үтте. Чарада илебезнең төрле төбәкләреннән килгән галимнәр, методистлар, мәктәпкәчә, гомуми һәм урта белем бирү учреждениеләре укытучылары катнашты. Сессиянең максаты – мәктәпкәчә, гомуми һәм урта һөнәри белем бирү системасының заманча халәтен анализлау һәм көнүзәк проблемаларның чишелешен табу.

---




17 нче гыйнвар көнне Арча район мәдәният йортында “Мин Арча баласы” проектының өченче сезоны ябылды. Бу сезонда проектта районның 500дән артык баласы һәм яшьләре катнашты һәм Арча районының тарихи объектлары турында 17 видеоролик төшерелде.

Безнең көллият студентлары (Гаранина Алиса, Бикчәнтәев Рөстәм , Мәҗитова Галия , Шакирова Аделина) да әлеге проектның җиңүчеләре булдылар. Аларга проект логотибы төшерелгән грамоталар һәм бүләкләр тапшырылды. Котлыйбыз!

---



25 нче гыйнвар – Студентлар көне уңаеннан Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студентлары Саба муниципаль районы “Дулкын” радиосында кунакта булдылар. Алар турыдан-туры оештырылган әңгәмә барышында көллият, студентлар тормышы, уку йортында эшләп килүче түгәрәкләр турындагы сорауларга җаваплар бирделәр, үзләре белән булган кызыклы вакыйгалар турында сөйләделәр, күңелләрендә булган хис-кичерешләре белән уртаклаштылар.

# *Студентлар көне белән!*

Кеше гомеренең иң күңелле чоры – студент еллары. Ул – һәр кеше тормышында иң шәп вакыт. Киләчәккә нигезләр салына, өметләр чынга аша, алда әле искиткеч идеяләр һәм зур казанышлар белән тулы тормыш көтә.

25 нче гыйнвар Студентлар көне буларак билгеләп үтелә. Әлеге көн Татьяна көне буларак та билгеле. Шул уңайдан Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студентларын да бәйрәмнәре белән котлыйбыз!

Хөрмәтле студентлар! Тормыш юлыгызда, барлык башлангычларыгызда уңышлар, саулык-сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телибез! Студент еллары тормыш китабыгызның мавыктыргыч, онытылмаслык бүлеге булып калсын! Югары максатлар куерга һәм аларга ирешергә курыкмагыз! Хыялларыгыз һәм кыю планнарыгыз тормышка ашсын! Бәйрәмегез күңелле үтсен!



# *Студент тормышы – иң күңелле вакытларның берсе*



Арча төбәге Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте белән дан тотканын барыбыз да белә. Моны көллиятебезне уңышлы тәмамлап, зур дәрәҗәгә ирешкән күренекле шәхесләр белән бәйләп була. Язучылар арасында Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Рифә Рахман, Сания Әхмәтҗанова, җырчылар арасында Булат Бәйрәмов, Рафил Җәләлиев, Илназ Гарипов һәм башкалар...

Мәктәпне тәмамлагач, уку йортына керү, һичшиксез, һәр студент өчен олы тормышка аяк басу, һөнәри юлыңны төзү, яхшы дуслар табу һәм үз сәләтеңне ачу – зур хыялдыр, минемчә. Мин 2021 нче елда мәктәпне тәмамлап, Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенә укырга кердем һәм нәкъ шушы уку йортында үземне таптым дисәм дә буладыр, мөгаен. Көллиятебездә без бик күңелле яшибез. Кырыйдан караганда, студент тормышы гел лекцияләрдән генә тора дип уйласагыз, нык ялгышасыз! Безнең көллиятезбездә үз сәләтләрен күрсәтергә теләгән студентлар өчен бик күп түгәрәкләр: бию, хор, баскетбол, волейбол, җиңел атлетика һәм башкалар да эшли. Күп вакыт безнең уку йортына төрле төбәкләрдән кунаклар килә. Алар безнең студентларның концерт номерларын гына түгел, көллиятебездә урнашкан “Әлифба” музееен да кызыксынып күзәтәләр.

Ә инде укуга килгәндә, мин укуны бик җиңел дип әйтмәс идем. Шулай да без бөтен куйган бурычларны үтәп, сессияләрне уңышлы ябабыз.

Мин 212 нче төркемдә укыйм. Төркемдәшләрем белән дус, тату, бердәм булып яшибез. Сыйныф җитәкчебез – Хузеева Клара Альбертовна. Ул һәрвакыт ярдәм итеп, яклап, киңәшләрен биреп, үз канаты астына җыеп, безне укытучы дөньясына алып бара.

Гомумән әйткәндә, мин бу белем йортына, укытучыларга һәм сыйныф җитәкчебезгә бик рәхмәтлемен. Чөнки биредә студентларга ныклы белем бирү белән бергә, тормыш мәктәбе серләренә дә өйрәтәләр.

Студент тормышы – иң күңелле вакытларның берседер. Тормышыгызда һәрвакыт белемгә, тапкырлыкка урын булсын!

***Сәйфеева Әлфия, 212 нче төркем***

# Тулай торакта яшәү – үзе бер бәхет

Студент тормышы – яңа танышу вакыты. Кемдер бу вакыт эчендә иң якын дусларын һәм үз мәхәббәтен дә таба. Көллиятебездә белемле һәм сәләтле укучыларны очратырга мөмкин. Алар арасында төрле төбәкләрдән килгәннәре дә бар. Татар, рус, чуваш, урдмурд, башкорт... Төрле милләттән булсак та, без Арча педагогия көллиятенең беренче тулай торак йортында дус, тату аралашып яшибез.

Безнең тулай торак бик матур, якты, заманча җиһазландырылган. Студентлар өчен барлык яхшы шартлар тудырылган. Беренче номерлы тулай торакта яшәве – үзе бер рәхәт...

Тулай торагыбызда студентлар советы эшләп килә, тәрбиячеләр белән бергә алда булачак эшләр планлаштырыла. Студентларны берләштерү, аларны тормышка әзерләү, укуга кызыксындыру өчен барлык көч куела.

Тулай торагыбызда бик күп төрле, берсеннән-берсе кызыклы бәйрәмнәр гел булып тора. Һәр бәйрәмгә киңәшләшеп, тырышып әзерләнелә. Студентлар матур итеп чыгыш ясыйлар, үз осталыкларын



күрсәтәләр. Мәсәлән, “Беренче курс студентлары көне”, “Талантлар күрсәтү киче”, “Квартирник” һәм башка бик күп төрле бәйрәмнәр...

Атна саен җомга көнне кино караулар, көндәлек бүлмә тикшерүләр, дәрес хәзерләүләр, имтиханга әзерләнүләр, ашханәдә бергәләп ашарга пешерүләр, күңелле матур кичләр студент тормышын тагын да ямьләндерә.

Гомумән алганда, тулай торакта яшьлекнең иң матур студент елларын уздыру өчен иң яхшы шартлар булдырылган.

**Баһаветдинова Диләрә, 311 нче төркем**









# Туган ягым – яшел бишек

Арча ягы – музейларга бай. 27 нче гыйнвар көнне Арча педагогия көллиятенең гимназия сыйныфлары “Казан арты” музеенда кунакта булдылар. Укучылар өчен Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” әсәре буенча экскурсия-сәяхәт үткәрелде. Музей хезмәткәрләре тарафыннан әсәрдән халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары чагылдырылган өзекләр уйналды. Экскурсия бик мавыктыргыч итеп оештырылган иде. Без шул вакыттагы мәдрәсә тормышы белән таныштык. Татар халкының күренекле бәйрәме – Сабантуйга бүләк җыю күренешен карадык. Әби-бабаларыбыздан калган йола, уен, бәйрәмнәрне искә төшердек.

Музей хезмәткәрләре тарафыннан Г. Бәшировның тормыш юлы һәм иҗатына тулы күзәтү ясалды. Экскурсия-сәяхәт Халык язучысына багышланган эчтәлекле күргәзмә карау белән тәмамланды.

**Абдуллина Дилә, 9нчы сыйныф**







# #ГИМНАЗИЯСУЛЫШЫ





















# ОСТАЗЛАРДАН ҮРНӘК АЛАБЫЗ...




2023 нче ел Россиядә педагог һәм остазлар елы дип игълан ителде. 90 елдан артык педагоглар әзерләүче Арча педагогия көллияте өчен бу аеруча куанычлы. Чөнки уку йорты тарихында тирән эз калдырган, аның бүгенге дәрәҗәсе өчен үзләреннән зур көч керткән остаз-педагогларыбыз бик күп. Шул уңайдан, 31 нче гыйнвар көнне гимназия сыйныфлары укучылары өчен Арча көллиятендә озак еллар эшләгән, тәҗрибәле, хөрмәткә лаек педагог-остазларыбыз, укытучылар гаиләсе Фәрит Фәтхиевич һәм Ольга Ивановна Минхаеровалар белән очрашу оештырылды. Кунаклар үзләренең көллияттә укыган һәм эшләгән елларындагы истәлекле хатирәләре, белем һәм тәҗрибәләре белән уртаклашты. Укучыларның сорауларына кызыклы җаваплар бирелде.

Остазларыбыз укучыларга үзләренең китапларын һәм дәүләт тарафыннан бирелгән медальләреннән күргәзмә дә оештырган иде. Аларның һәрберсе белән бәйле истәлекләр дә сөйләнде. Фәрит Фәтхиевичны укучылар моңа кадәр туризм һәм спорт остасы буларак белсәләр, бүген аны үткен телле шагыйрь һәм үз әсәрләрен мавыктыргыч итеп җиткерә белүче актер буларак та ачтылар. Тормыш иптәше Ольга Ивановна да үзе язган шигырьләре аша, укытучы һөнәренә тугры булып яшәвен һәм остазларына гомере буе рәхмәтле булуын дәлилләде. Очрашу-чара укучылар өчен файдалы һәм мавыктыргыч булды.

# *БЛОКАДА ИКМӘГЕ*

Ленинград 1941 елның 8 сентябреннән 1944 елның 27 гыйнварына кадәр – 872 көнгә камалышта кала. Анда яшәүчеләр өчен бу иң авыр 872 көн була. Зур шәһәрләрне шулай озак саклау буенча фактлар хәтта дөнья тарихында да юктыр. Ленинградның тиңдәшсез батырлыгы тарихка халыкның гаҗәеп кыюлыгы һәм геройлыгы эпопеясы булып кереп кала. Бу көннәрдә “Блокада икмәге” Бөтенроссия хәтер акциясе үткәрелә. Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте дә моңа кушылды.




**Редколлегия:** Г.Х. Шиһабеддинова

Сәйфеева Ә., Баһаветдинова Д., Абдуллина Д.